Дәvләт учреждениесе консультанты биржа килешvләрендә акча эшләргә ниятләп, 1,1 миллион сумнан артык акча югалткан.
России Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча беренче ОПга мошенниклык турындагы гариза белән 37 яшьлек жирле хатын-кыз морәжәгать иткән. Зыян кvрvче сvзләренчә, узган елнын ноябрь башында танышу сайтында ана vзен Михаил дип таныштырган ир-ат язган. Алга таба язышу барышында ул ана vзенен финанс хәлен яхшыртырга тәкъдим итә, һәм анын тәкъдиме буенча ул янәсе финанс аналитигы белән мессенджерда аралаша башлый.      Алтын, акцияләр һәм валютада акча эшләргә ниятләп, хатын-кыз vз телефонына ике кушымта урнаштырган һәм әнгәмәдәш инструкцияләре буенча, балансны 30 мен сумга тулыландырган. Аннары ул куратор белән берлектә компанияләрнен берсенен акцияләрен сатып алу буенча торле килешvләр vткәрә башлый. Ана бер миллион сумнан да ким булмаган акча кертергә кинәш иткәннәр. Морәжәгать итvче 521 мен сумлык ике кредит рәсмиләштергән һәм алар белән vз счетын тулыландырган, ә аннары жибәрелгән реквизитлар буенча акчаны криптовалюта счетына кvчергән. Анын табышы vсә башлавына илһамланып, ул шикле Финанс операцияләрен дәвам итә.
Берникадәр вакыттан сон ана килешv суммасы 15 000 доллардан артып китvе турында хат килгән, шуна бәйле рәвештә икенче дәрәжәдәге иминиятләштерv беркетмәсен тоташтырырга кирәклеге әйтелгән. Нәтижәдә хатын-кызга тагын 250 мен сумлык ике кредит алырга һәм аларны куратор кvрсәткән счетларга кертергә туры килгән. Мона карамастан анын шәхси кабинеты блокланган була, һәм ул сәvдә мәйданчыгынын техник хезмәтенә морәжәгать яза. Анын белән юрист элемтәгә кергән, ул элегрәк vзе дә анламыйча, мошенниклар белән аралашкан, һәм анын тарафыннан тотылган ботен акчаны кире кайтарырга тырышачак, дип анлаткан.
Билгесезгә ышанып, агымдагы елнын 3-20 январында хатын-кыз, юрист vтенече буенча, ачык криптовалюта янчыгына берничә кvчерv башкарган. Кабул итvләр суммасы 28 000 сумнан 87 000 сумга кадәр житкән. Ләкин биржа килешvләренә салынган акчаны ана кире кайтармаганнар. Бу вакыт эчендә аны алдаганнар дип уйлап, ул полициягә морәжәгать итә. Нәтижәдә морәжәгать итvче 1 132 350 сум югалткан.
Хәзерге вакытта жинаятьчеләрнен кайда булуын ачыклауга юнәл-дерелгән оператив-эзләv чаралары комплексы vткәрелә. Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск шәһәре буенча идарәсе искәртә. Таныш булмаган затлар vтенече буенча акчалата операцияләр ясамагыз, смс-банкинг аша килгән парольләрне беркемгә дә хәбәр итмәгез, интернет-белдерvләр аша товар сатып алганда һәм сатканда алдан тvләvгә яки акчаларны алмаштыруга риза булмагыз.